ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 39 от « 09 » 02 2022 г.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге)
һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге
248-ФЗ номерлы чараларны гамәлгә ашыру хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 14 гыйнварындагы 04-51/197 номерлы хаты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныргa:

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 14 гыйнварындагы «Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 25 номерлы карары;

1.2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 30.01.2012 елның 30 январендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 90 номерлы карары;

1.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 ноябрендәге «Мамадыш муниципаль районы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» 1378 номерлы карары;

1.4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 ноябрендәге «Мамадыш муниципаль районы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 1379 номерлы карары;

1.5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 29 декабрендәге «Мамадыш муниципаль районы территориясендәге җирләрдән файдалану бкуенча муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1189 номерлы карары;

1.6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 3 февралендәге «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 80 номерлы карары;

1.7. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 29 декабрендәге «Мамадыш муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген раслау турында» 2567 номерлы карары;

1.8. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 июлендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 826 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов